**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ПРИКАЗ

---

20.05.2019 № 1/2019 г.Казань 20.05.2019 № 153

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының аерым боерыкларының үз көчен югалтуын тану турында

2018 елның 22 июнендәге УП- 454 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» Татарстан Республикасы Президентының Указы нигезендә

**боерабыз:**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип танырга:

2016 елның 24 февралендәге 103 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм яклар конфликтын көйләү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы комиссиясен төзү турында»;

2016 елның 24 февралендәге 104 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре вазыйфаларын башкаручы затларның вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында»;

2017 елның 20 июлендәге 474 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык

хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында»;

2017 елның 12 сентябрендәге 592 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын башкаруга (кадрлар резервына кертүгә) бәйге үткәрү турында Нигезләмәне раслау турында»;

2018 елның 19 мартындагы 121 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында коррупция куркынычлары булган эшкә билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»;

2018 елның 21 мартындагы 134 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 24 февралендә кул куелган 103 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм яклар конфликтын көйләү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында».

Татарстан Республикасы
спорт министры — В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
яшьләр эшләре министры — Д.И.Фаттахов